**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 14 мартындагы 700 номерлы карары**

**«Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль биремне формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында»гы карарның 3 пунктын үтәү йөзеннән һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 һәм 78.1 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 14 мартындагы
700 номерлы карарына
кушымта

**«Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен «Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Идарә) гамәлгә ашыра торган «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – Учреждение) тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль биремне формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү тәртибе турында»гы карарының 3 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 һәм 78.1 статьялары нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Тәртип нигезендә билгеләнгән, чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) муниципаль биремне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидия күләмен исәпләгәндә кулланыла торган эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар (алга таба – эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет ассигнованиеләре нигезләмәләрен формалаштырганда исәпкә алына.

1.3. Эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар Учреждение тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләгәндә кулланыла.

1.4. Муниципаль биремдә эш башкару күләме күрсәткечләре билгеләнгән очракта, эш башкаруга норматив чыгымнар эш күләме берәмлегенә исәпләнә. Бер типка кертеп булмый торган эшләр башкарылган очракта, аларны үтәүгә чыгымнар смета ысулы белән исәпләнә.

1.5. Муниципаль бирем кысаларында башкарыла торган һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә (башкарыла) торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлегенә кертелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар һәр эш өчен өч елга раслана.

1.6. Учреждениегә муниципаль биремне үтәүгә бүлеп бирелгән субсидия күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль биремне формалаштыру белән бер үк вакытта исәпләнә.

1.7. Эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

- расланган штат расписаниесе;

- эшләрне башкару өчен кирәкле нормалар, шул исәптән: Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 2 августындагы 1006 номерлы «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы сакланган булуына таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында»гы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 11 февралендәге 176 номерлы «Мәдәният өлкәссендәге объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы сакланган булуына таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында»гы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 6 мартындагы 202 номерлы «Спорт объектларының террорчылыкка каршы сакланган булуына таләпләрне һәм спорт объектларының куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында»гы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 6 октябрендәге 1648 номерлы «Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык һәм аның карамагындагы оешмалар объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы сакланган булуына таләпләрне һәм Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык һәм аның карамагындагы оешмалар объектларының (территорияләренең) куркынычсызлык паспорты формасын раслау турында»гы карары, Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр күпләп җыела торган урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы сакланган булуына таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортлары формаларын раслау турында»гы карары, дәүләт хакимияте федераль органнарының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге норматив хокукый актлары, шулай ук ГОСТлар, Төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Санитария нормалары һәм кагыйдәләре, федераль стандартлар һәм эш башкару регламентлары белән расланган нормалар (алга таба – товарларны куллануның, эшләрдән файдалануның расланган нормалары);

- Татарстан Республикасының яисә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары белән расланган коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормалары (алга таба – коммуналь ресурсларны куллануның расланган нормалары). Учреждение тарафыннан башкарыла торган эшкә карата товарлардан, хезмәтләрдән, коммуналь ресурслардан файдалануның натураль күрсәткечләрдә белдерелгән расланган нормалары булмаган очракта, натураль күрсәткечләрдә белдерелгән нормалар Учреждение эшчәнлегенә анализ һәм аның күрсәткечләрен, эш башкару сыйфатына карата таләпләрне үтәп, эш берәмлеген башкару өчен чыгымнарның минималь күләменә китереп уртачалау нигезендә яисә эшне башкаручы Учреждение буенча медиана зурлыгы нигезендә билгеләнә.

1.8. Эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар, эшләрне башкаруга смета ысулы белән исәпләнгән чыгымнар бюджет ассигнованиеләре күләмен арттыруга китерә алмый.

1.9. Эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны, эшләрне башкаруга смета ысулы белән исәпләнгән чыгымнарны исәпләгәндә, финанс белән тәэмин ителеше башка максатчан субсидияләр рәвешендә гамәлгә ашырыла торган чыгымнар исәпкә алынмый.

1.10. Учреждениенең (шул исәптән аның янәшәсендәге территориянең) эшләр башкарганда файдаланылмый торган милкен карап тотуга чыгымнар эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә), смета ысулы белән исәпләнгән эшләрне башкаруга норматив чыгымнар бәясенә керми.

1.11. Эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) һәм аларны үзгәртүгә норматив чыгымнар, шулай ук смета ысулы белән билгеләнгән эшне башкаруга чыгымнар Казан шәһәре Башкарма комитетының Учреждение тарафыннан

эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) чыгымнар нормативларын раслау турындагы аерым карары белән раслана.

1.12. Эшләрне башкаруга норматив чыгымнар Интернет челтәрендә рәсми сайтта урнаштырылырга тиеш.

## II. Эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны, эшләрне башкаруга смета ысулы белән исәпләнгән чыгымнарны исәпләү

2.1. J эшне башкаруга норматив чыгымнар (Nj) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Nj = Nj^{НЕПОС} + Nj^{ОБЩ} + Nj^{ЗАК}$$, биредә:

$Nj^{НЕПОС}$ – j эшне башкаруга турыдан-туры бәйле норматив чыгымнар;

$Nj^{ОБЩ}$ – j эшне башкару өчен гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнар;

$Nj^{ЗАК}$ – муниципаль бирем күләменең бер өлешен үтәүгә юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне җәлеп итеп, j эшне (хезмәт күрсәтүне) башкаруга бәйле норматив чыгымнар.

2.2. J эшне башкаруга турыдан-туры бәйле норматив чыгымнар составында түбәндәге чыгымнар төркемнәре исәпкә алына:

- эш башкаруда турыдан-туры катнашучы персоналның хезмәте өчен түләүгә һәм хезмәт хакына өстәмә билгеләнгән түләүгә;

- файдалы куллану вакытын исәпкә алып, эшләрне башкару барышында кулланыла торган (файдаланыла торган) матди запаслар сатып алуга (шул исәптән аренда түләүләренә чыгымнар);

- турыдан-туры j эш башкаруга бәйле башка чыгымнар.

2.3. Гомумхуҗалык ихтыяҗлары өчен норматив чыгымнарга эшләр башкару белән турыдан-туры бәйле һәм норматив чыгымнарга кертеп булмый торган чыгымнар керә.

Гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарга түбәндәге чыгым төрләре керә:

- коммуналь хезмәтләргә (милекне карап тотуга норматив чыгымнар составында исәпкә алына торган чыгымнардан тыш);

- эшне башкаруда турыдан-туры катнашмый торган административ-идарә, хезмәт күрсәтү һәм башка персоналга хезмәт өчен түләүгә һәм хезмәт хакына өстәмә билгеләнгән түләүләргә;

- элемтә хезмәтләрен сатып алуга;

- транспорт хезмәтләрен сатып алуга;

- күчемсез милектән файдалануга (куллануга);

- эшләр башкару өчен турыдан-туры кулланыла торган аеруча кыйммәтле күчемле милектән файдалануга (куллануга);

- эшләрне башкару бәясенә йогынты ясый торган башка чыгымнар.

2.4. Муниципаль бирем күләменең бер өлешен үтәүгә юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне җәлеп итеп башкарыла торган норматив чыгымнарга коммерция тәкъдимнәрендә булган смета исәпләүләре, расланган прайслар кулланыла.

2.5. Турыдан-туры j эшне башкаруга бәйле норматив чыгымнар ($Nj^{НЕПОС}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Nj^{НЕПОС} = Nj^{ОТ1} + Nj^{МЗ} + Nj^{ИНЗ},$$ биредә:

$Nj^{ОТ1}$– j эшне башкаруга турыдан-туры катнашучы персоналга хезмәт хакына һәм хезмәт хакына өстәмә билгеләнгән түләүләргә чыгымнар;

$Nj^{МЗ}$ – файдалы куллану вакытын исәпкә алып, j эшне башкару барышында кулланыла (файдаланыла) торган матди запаслар сатып алуга чыгымнар (шул исәптән аренда түләүләренә чыгымнар);

$Nj^{ИНЗ}$ – турыдан-туры j эш башкаруга бәйле башка чыгымнар.

2.6. Эшләрне башкаруга турыдан-туры бәйле чыгымнарны конкрет эшкә кертү мөмкин булмаган очракта, эшләр башкаруга турыдан-туры бәйле чыгымнар күләмен эш башкаруга турыдан-туры бәйле булган хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарына пропорциональ рәвештә конкрет эшләргә кертү юлы аша гамәлгә ашырыла.

2.7. Учреждение берничә эш башкарган очракта, эшләр буенча гомумхуҗалык ихтыяҗлары чыгымнарын бүлү гомумхуҗалык ихтыяҗлары өчен чыгымнар күләмен эшләрне башкаруга турыдан-туры бәйле хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүгә булган чыгымнарга пропорциональ рәвештә конкрет эшләргә кертү аша башкарыла.

2.8. Гомумхуҗалык ихтыяҗларына j эш өчен норматив чыгымнар ($Nj^{ОБЩ}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Nj^{ОБЩ} = Nj^{КУ} + Nj^{СНИ} + Nj^{СОЦДИ} + Nj^{УС} + Nj^{ТУ} + Nj^{ОТ2} + Nj^{ПНЗ},$$ биредә:

$Nj^{КУ}$ – j эш өчен коммуналь хезмәтләргә чыгымнар;

$Nj^{СНИ}$ – j эш башкару барышында файдаланыла торган күчемсез милек объектларын карап тотуга чыгымнар (шул исәптән аренда түләүләренә чыгымнар, салымнар түләүгә чыгымнар);

$Nj^{СОЦДИ}$ – j эш башкару барышында файдаланыла торган аерым кыйммәткә ия күчемле милек объектларын карап тотуга чыгымнар (шул исәптән аренда түләүләренә чыгымнар, салымнар түләүгә чыгымнар);

$Nj^{УС}$ – j эш өчен элемтә хезмәтләрен сатып алуга чыгымнар;

$Nj^{ТУ}$ – j эш өчен транспорт хезмәтләре сатып алуга чыгымнар;

$Nj^{ОТ2}$ – эш башкаруда турыдан-туры катнашмый торган хезмәткәрләргә (административ-идарә, административ-хуҗалык, ярдәмче һәм башка персонал) хезмәт хакына һәм хезмәт хакына өстәмә билгеләнгән түләүләргә чыгымнар;

$Nj^{ПНЗ}$ – j эш өчен башка гомумхуҗалык ихтыяҗларына чыгымнар.

2.9. j эш башкаруга норматив чыгымнарны билгеләгәндә исәпкә алына торган матди запаслар бәясе һәм коммуналь хезмәтләр тарифы сатып алу планлаштырыла торган матди запасларга, коммуналь хезмәтләргә охшаш, ә андыйлар булмаганда – Россия Федерациясе Бюджет кодексының 173 статьясы нигезендә эшләнә торган Россия Федерациясенең социаль-икътисади үсешен фаразлау буенча билгеләнә торган тиешле финанс елында уртача булган куллану бәяләренең фаразланган индексын исәпкә алып, бертөрле матди запасларга, коммуналь хезмәтләргә базар бәяләре (тарифлар) турындагы мәгълүмат нигезендә билгеләнә.

J эшне башкаруга норматив чыгымнарны билгеләгәндә исәпкә алына торган эшләр һәм хезмәтләрнең бәясе сатып алу планлаштырыла торган эш һәм хезмәт бәяләренә охшаш булганнарга базар бәяләре турындагы мәгълүмат нигезендә билгеләнә.

2.10. Смета ысулы белән билгеләнгән эшләрне башкаруга чыгымнарны исәпләгәндә, эшләрне башкаруга норматив чыгымнарны исәпләгәндәге шул ук чыгымнар төркемнәре исәпкә алына.

2.11. Эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны һәм смета ысулы белән билгеләнгән эшләрне башкаруга чыгымнарны исәпләгәндә, чыгымнарның гомуми суммасы бер мең сумга кадәр түгәрәкләнә.

2.12. Эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар, шулай ук смета ысулы белән билгеләнгән эшләрне башкаруга чыгымнар түбәндәге чыгымнар төркемнәре буенча раслана:

- эшләр башкаруда турыдан-туры катнашучы персоналның хезмәте өчен түләүгә һәм хезмәт хакына билгеләнгән өстәмә түләүгә;

- файдалы куллану вакытын исәпкә алып, эшләрне башкару барышында кулланыла торган (файдаланыла торган) матди запаслар сатып алуга;

- эшләрне башкаруга турыдан-туры бәйле башка чыгымнар;

- коммуналь хезмәтләргә;

- административ-идарә, хезмәт күрсәтүче һәм расланган штат расписаниесе нигезендә эшләрне башкаруда турыдан-туры катнашмый торган башка персоналга хезмәт хакын түләүгә һәм хезмәт хакына билгеләнгән өстәмә түләүгә;

- элемтә хезмәтләрен сатып алуга;

- транспорт хезмәтләре сатып алуга;

- күчемсез милек объектларын карап тотуга;

- эшләрне башкаруда турыдан-туры кулланыла торган муниципаль биремне үтәү өчен кирәкле аеруча кыйммәтле күчемле милек һәм милек объектларын тотуга;

- эшне башкару бәясенә йогынты ясый торган башка гомумхуҗалык ихтыяҗларына.

**III. Эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә)**
**норматив чыгымнарны раслау тәртибе**

3.1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) Тәртип нигезендә исәпләнгән норматив чыгымнар Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына җиткерелгән лимитлар күләме чикләрендә раслана.

3.2. Муниципаль биремне үтәү вакыты дәвамында Тәртип нигезендә билгеләнә торган норматив чыгымнарны үзгәртү норматив хокукый актларга, шул исәптән Учреждениенең эшләр башкаруга турыдан-туры бәйле хезмәткәрләренә (аерым категория хезмәткәрләренә) түләүләр күләмнәрен билгели торган норматив хокукый актларга муниципаль бирем үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен үзгәртүгә китерә торган үзгәрешләр кертелгән очракта башкарыла (кирәк булганда).

______________________